**А.Ф.Юсупов, Н.М.Юсупова**
*Казанский (Приволжский) федеральный университет*

# XX гасыр башы татар поэзиясе теленең стилистик үзенчәлекләре (Дәрдемәнд әсәрләре мисалында)

*стиль, поэтический язык, Дардменд, стилистические фигуры, символ*

Татар әдәби теле тарихында XX йөз башы күптөрле стилистик эзләнүләр алып барылган, гасырлар дәвамында үстерелеп килгән югары стильнең сөйләм стиле белән кушылуы чоры буларак билгеләнә. Әлеге эзләнүләр шигъри әсәрләр телендә аеруча көчле яңгыраш алып, барлык шагыйрьләр иҗатын колачлый, чөнки нәкъ менә шигърият теле сыгылмалы, образлы, бай сурәтлелеккә ия булуы белән аерылып тора. Бер яктан, шәркый юнәлештәге югары стиль, аңа хас стилистик берәмлекләр кулланылышын дәвам итә. Икенче яктан XX гасыр башында халыкның сөйләм теленә нигезләнгән татар әдәби теле формалашып җитә һәм «матур әдәбиятның жанр һәм стиль ягыннан баюына, функциональ стильләрнең формалашып җитүенә китерә» [Хаков 2003: 196].

Әлбәттә, бер мәкалә чикләрендә генә әлеге чор шигъри әсәрләрнең телен тулаем тикшерү, анализлау мөмкин түгел, бу материалда Дәрдемәнд шигырьләрендә киң кулланылышка ия стилистик фигуралар гына тикшерү үзәгенә куела. Әдип үзенең әсәрләрендә милли телнең стилистик байлыгын тулы файдалана. Фикерне сурәтле, сәнгатьчә йогынтылы, образлы итүгә ирешү юлында ул стилистик берәмлекләр, фигураларның шигъри мөмкинлекләрен тулысынча файдалана.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Дәрдемәнд шигырьләрендә киң кулланылышка ия сурәтләү чарасы буларак чагыштырулар аерылып чыга. Дәрдмәнд иҗатында бер контекст эчендә генә дә берничә чагыштыру төзелмәсе кулланылган очраклар бар. Мисал өчен: *Буран өермә бөтерәдер, / Уйный, кар җирдән ала: / Я* ***җанварлардай үкерәдер****, / Я* ***егълый гүя бала****. / Я бер* ***крыша ябучыдай*** */ Түбә саламын* ***чәчә****, / Я кич калган бер* ***юлчыдай****, / Тәрәзә капкачын* ***әчә****.* («Кышкы төн», 1907).

Шигырь кысаларында буран бер үк вакытта җанвар, егълаган бала, крыша ябучы, юлчы белән чагыштырыла, шул юл белән шагыйрь катлаулы сурәтлелек тудыруга ирешә, ләкин һәр чагыштыру объектының төрле билгесе чагыштыру өчен нигез булып тора: җанварның үкерүе, баланың егълавы, тәрәзә ябучының чәчү үзлеге, юлчының тәрәзәне ачуы чагыштыру өчен нигез буларак кулланылган.

Чагыштыруның стилистик, образ тудырудагы үзенчәлеге турында сүз йөрткәндә, аның формасы, төзелеше, нинди лексик-грамматик чаралар ярдәмендә ясалышына да игътибар итү мөһим. Чагыштыру

төрле кушымча, бәйлек, теркәгеч, мөстәкыйль сүз, мөнәсәбәтле сүзләр белән белдерелергә мөмкин. Дәрдемәнд әсәрләрендә чагыштырулы конструкцияләрдә кушымчалар актив кулланыла:

*Куйдым башымны кулларым өстенә дә, яттым, / **Үлектәй узандым**, дидем аллага тәвәккәл.* («Аллага тәвәккәл!», 1911)

Узандым – сузылдым. / *Әгәрчә дәүләтем юктыр җитәрлек, / **Ишәктәй** һәм йөк астында түгелен.* (“***”)

*Авыз ачып сөйләргә тел кайрадым, / **Өйрәнчек бала коштай**, баш **сайравым**.* (“***”)

Ике предметны чагыштыру өчен телдә бәйлекләр кулланылган очрак та теркәлде: *Омтылган **иләк кебек йөрешләре**, / Ул моңлы, матур күз сөзешләре.* (“***”)

Дәрдемәнд әсәрләрендәге чагыштыру конструкцияләрендә *әйтерсең* теркәгеченең алынма синонимы *санкем* кулланылган очрак та күзәтелә. Бу күренешнең шул чор татар шигъриятендә киң таралмаган булуын да ассызыклап кую мөһим: *Ним сабыйдыр ул сабыйлык көннәрен бик сагына, / **Санкем** угыл, кыз туен итмәктә ул, кызган уен.* («Хәят», 1908)

Дәрдемәнд үзенең шигырьләрендә традицион чагыштыру төзелмәләрен дә куллана. Мәсәлән, бер-берсен сөйгән ярларны Сак һәм Сок белән чагыштыру – халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә, матур әдәбият әсәрләрендә дә киң таралган күренеш: *Бу көндә **Сак белән Соклар** кебек без...*

Дәрдемәнд әсәрләрендә эмоциональ тасвирлау чарасы буларак эпитетлар да киң кулланылышка ия. Шагыйрь күренешләрне тасвирлаганда аеруча төс билгесен белдерә торган эпитетларны яратып куллана. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, алар, нигездә, табигать күренешләрен тасвирлаганда уңышлы кулланылалар. Мәсәлән, аның шигырьләрендә еш кына *сары* эпитеты *юл* сүзе белән янәшә килә. Тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк: авторның шигырьләрендә ак төс өстенлек итсә, истәлек-парча һәм хикәяләрендә яшел төс күбрәк кулланыла. Моннан тыш Дәрдемәнд үзенең әсәрләрендә татар әдәбиятында киң таралган һәм эпитет тәшкил иткән *нечкә бил, татлы йокы, тирән йокы* төзелмәләрне дә яратып куллана: *Әгәр барсаң, **саба җил**, безнең илгә, / Сәламләр әйт, сәлам ул **нечкә билгә**. (“***”)*

Шуның белән янәшәдә Дәрдемәнд еш кына табигать күренешләрен җанландыру алымынннан иркен файдалана. Әдип абстракт төшенчәләрне дә җанландыра, шул рәвешле шигырьләренең тәэсир көчен арттыруга ирешә. Шагыйрь, тигезсезлек мөнәсәбәтен белдерә торган алымнарны (гипербола һәм литота) кулланып, үзенчәлекле сурәтләр ясый.

Дәрдемәнд иҗатында киң кулланылышка ия стилистик фигураларның тагын берсе – символлар. Хәтта чор әдәбиятында ул төп символист шагыйрь буларак танылу ала. Дәрдемәнд иҗатында

символлар, бердән, Яңа яшәеш моделен төзү, фәлсәфи күзаллауны булдыруда, икенчедән, милләт тормышына бәя бирүдә, мөнәсәбәт белдерүдә ярдәмгә килә, «яшәешнең, вакытның агышын, мәңгелек канунын ачарга ярдәм итәләр» [Саяпова 2006: 156]. Г. Халит аны болай бәяли: «әлеге концепция Дәрдемәнд иҗатында поэзияне, шигырь сәнгатен идеаллаштыруда һәм шуңа нисбәтән шигъри сүзнең нечкәлеген, нәфислеген, гүзәллеген табарга тырышуда күренә; икенчедән, дөнья, табигать гармониясен, аның фәлсәфи, рухи һәм шигъри серен ачарга теләү рәвешендә гәүдәләнә» [Халит 2002: 271].

Мисал өчен, Дәрдемәнднең атаклы «Кораб» (1908) шигыре тулысынча символлар белән язылган (*диңгез – тормыш, шаулавы – вакыт агышы, җил илдә барган үзгәрешләр, дулкын – язмыш, тормышны үзгәртердәй көч)*. Символлар кулланып, шагыйрь ил-халыкның киләчәге өчен кайгылы-борчылулы кинаясен бөтен тулылыгы белән чагылдыра алган. Шагыйрьнең иң билгеле «Җәй үтте...», «Кораб» (1908), «Без» (1908), «Бүзләрем маналмадым...» (1908), «Хәят» (1908), «Ятам кайчаклары моңлап...» һ.б. шигырьләрен алсак та, суфичыл символларның киң кулланылуы күренә. Татар әдәбиятында символларга киң таяну, гомумән, суфичыл юнәлештәге шигъри әсәрләрдән юл ала [Юсупова 2015: 209]. *Өн, су, мәләк, туй, кояш, шәм, көн, таң, ай, болыт, яз, чокыр, кыш, шоңкар, аккош, җил, тау, талчыбык, яз чәчәге, кырмыска* кебек символлар шагыйрьнең фәлсәфи шигырьләрендә кабатланып килә торган символларга әйләнә. Мәсәлән, «Тиң булырмы йолдыз тулган айга...» шигырендә Дәрдемәнд *йолдыз* һәм *тулган ай* символик образларына мөрәҗәгать итә. Суфичылык символикасы кысаларында *ай – матур кыз – Аллаһ* янәшәлеге күзәтелә. Мәсәлән: *Ялвару кирәкмәс, кирәк наз гына, / Ул да – урыны белән, аз-аз гына!*

Биредә матур кызга омтылган йолдыз Аллага мәхәббәт тотучы суфины аңлату өчен кулланыла. Моннан тыш Дәрдемәнднең «Рәнеҗ хәтер...», «Исәрме яз җиләс җилләр», «Булырмы яз, исеп җилләр...», «Җәй үтте...» һ.б. шигырьләрендә *яз* һәм *кыш* символларына еш мөрәҗәгать ителә. Шигырьләрдә алар лирик геройның күңел халәтен җиткерергә ярдәм итә, кеше гомеренең этапларын, мәңгелектәге яшәеш циклларын төгәлләштерә.

Шул рәвешле, Дәрдемәнднең шигъри әсәрләре телендә күпгасырлык классик шигъри телгә хас үзенчәлекләр саклана. Шулай ук символик әдәбиятның төп үзенчәлеге – яшерен мистик эчтәлекне ачу өчен, күчерелмә мәгънә белән бәйле стилистик алымнар, сыйфатлау чараларына еш мөрәҗәгать ителә. Дәрдемәнднең шигырьләре, фикерләү рәвеше һәм поэтикасы татар әдәбиятының иң югары ноктасы булып таныла. Күләме ягыннан зур булмаган, әмма тирән эчтәлекле, фәлсәфи һәм форма ягыннан камил булган Дәрдемәнд әсәрләре төрки халыклары әдәбиятында үрнәк булып санала.

*Мәкалә № 18-412-160008 проекты кысаларында РФФИ һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең гранты нигезендә башкарылды.*

**Әдәбият**

Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской litерерaтуре / А.М.Саяпова. – Казань: Алма-Лит, 2006. – 246 с.

Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан) / В.Х.Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 295 б.

Халит Г. Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе / Г.Халит // Бертуган Рәмиевлар: Фәнни-биографик җыентык. – Казан: Рухият, 2002. – Б. 256–278.

Юсупова Н.М. Символизация в тюрко-татарской поэзии средневековья и нового времени (на примере суфийских поэтических произведений) / Н.М.Юсупова, А.Ф.Юсупов // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2015. – № 10(52). – Ч. 2. – С. 209–211.